КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 6 сентябрь г.Казань № 797

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2009 ел, 8 май, 287 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2009 ел, 8 май, 287 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 19 май, 388 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1040 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 7 март, 195 нче; 2012 ел, 10 октябрь, 844 нче; 2013 ел, 19 март, 193 нче; 2013 ел, 18 июль, 501 нче; 2013 ел, 22 август, 592 нче; 2013 ел, 7 ноябрь, 859 нчы; 2014 ел, 23 гыйнвар, 30 нчы; 2014 ел, 22 октябрь, 773 нче; 2015 ел, 11 июнь, 426 нчы; 2017 ел, 16 март, 148 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1072 нче; 2018 ел, 8 август, 643 нче; 2018 ел, 29 октябрь, 952 нче; 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче; 2019 ел, 29 апрель, 359 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы турындагы нигезләмәгә, 3.3 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләргә, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин